**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт,Актаныш ав.,423740

Тел. (85552) 3-44-22, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_______________ ___________

Мәҗбүри эш төрләрен һәм мәҗбүри эш рәвешендә административ җәза үтәлә торган оешмалар исемлеген билгеләү турында

Мәҗбүри эш рәвешендәге административ җәза билгеләгән затларны төзәтү, аларда нормаларга, җәмгыять кагыйдәләренә, иҗтимагый-файдалы хезмәткә хөрмәт уяту максатында, административ хокук бозу турында Россия Федерациясе Кодексының 32.13 статьясы нигезендә, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районы территориясендә административ җәзаны үтәү өчен мәҗбүри эш төрләрен, 1 нче кушымта нигезендә расларга.
2. Мәҗбүри эш төрендәге административ җәза җибәрелгән оешмаларның исемлеген, 2 нче кушымта нигезендә расларга.
3. Күрсәтелгән административ җәза билгеләнгән затларның, яшәү урыны буенча мәҗбүри эшләрне башкарырга.
4. Россия суд приставлары Федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Актаныш район суд приставлары бүлегенә, 2 нче кушымтада күрсәтелгән оешмаларга хокукый һәм методик ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәргә.
5. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәҗбүри эш төрләрен һәм мәҗбүри эш рәвешендәге административ җәза үтәлә торган оешмалар исемлеген раслау турында» 2021 елның 22 мартындагы, 48 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
6. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN .RU) урнаштырырга.
7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфасын башкаручы Р.А.Ильясов

Татарстан Республикасы
Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
__________________ №___
1 нче кушымта

Актаныш муниципаль районы территориясендә административ җәза үтәү өчен мәҗбүри эш төрләре

1. Паркларны, ял зоналарын, урамнарны, җәмәгать файдалануындагы территорияләрне төзекләндерү, җыештыру, яшелләндерү, чүп-чардан чистарту.

2. Тарихи-архитектура һәйкәлләрен, ял итү зоналарын, мәдәният паркларын торгызу һәм саклау, яшелләндерү, утырту, чүп үләннәрен утау, газоннарны, чәчәк түтәлләрен сугару, агарту, агач һәм куак утырту, агачларны кисү һәм җыю, үләннәрне һәм коры-сарыларны чабу, җәмәгать файдалануындагы территорияләрдә коелган яфракларны чистарту.

3. Юл техникасы өчен мөмкин булмаган урыннарда, юл өслекләрен пычрактан, чүп-чардан һәм кардан чистарту.

4. Тротуарларны, тротуар плитәләрен чистарту, урамнарны себерү, тротуарлар һәм керү юллары салганда билгеле бер квалификация таләп итми торган ярдәмче эшләр.

5. Иҗтимагый куллану территорияләрендә кече архитектура формаларын буяу.

6. Автобус тукталышларын төзекләндерү һәм җыештыру.

Татарстан Республикасы
Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
_________________ №-___
2 нче кушымта

Актаныш муниципаль районы территориясендә мәҗбүри эш рәвешендә административ җәза үтәлә торган оешмалар исемлеге

| № | Оешмалар |
| --- | --- |
| 1 | “Коммунсервис” МУП Актаныш, ИНН 1604011286, адресы: Актаныш авылы, Ленин проспекты, 58 йорт, кв.2. |
| 2 | Район үзәк хастаханәсе, ИНН 1604000982, адресы: Актаныш авылы, Ленин проспекты, 1нче йорт. |
| 3 | Актаныш авыл Башкарма комитеты, ИНН 1604006783, адресы: Актаныш авылы, Ленин проспекты, 58 йорт. |
| 4 | МУП “Актаныш ТБО полигоны”, ИНН 1604009135, адресы: Актаныш ав., Юл ур., 44 й. |
| 5 | Актаныш муниципаль районының авыл җирлекләре муниципаль берәмлекләре Башкарма комитетлары |